СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №32 (7205) | 19 март, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

Тавыш бирү нәтиҗәләре

Районда ССР Союзын саклап калу буенча үткәрелгән референдум нәтиҗәләре түбәндәгечә булды. Исемлеккә кертелгән гражданнарның 90,1 проценты тавыш бирергә килде. Аларның 93,9 проценты ССР Союзын саклауны яклап чыкты, «Әйе» дип тавыш бирде. 5,2 процент кеше референдумга куелган сорауга каршы тавыш бирде. 0,9 процент бюллетень дөрес түгел дип табылды.

Бердәм Совет иле өчен

Бер кешедәй булып

Авыл уртасындагы «Алга» колхозы идарәсе бинасы янында бәйрәмчә киенгән халык төркеме иртәнге якта аеруча күп булды. Иң иртәләгәннәре—колхозчы Сәхип Сәгъдиев, бригадир Илгиз Ибраһимов, механизаторлар Фаикъ Фәттахов, Илсөяр Насыйбуллин иң беренчеләрдән булып кулларына бюллетень алдылар.

Иртәнге кыска гына җыелышта пенсионер, заманасында колхозның иң авыр эшләрен тарткан Рәшидә апа Хөснетдинова, пенсионер-инвалид Гаваз ага Шәмиев һәм бүген иң яшь тавыш бирүчеләрнең берсе Раикъ Мостафинга истәлек бүләкләре тапшырылды. Раикъ бердәнбер яшь тавыш бирүче түгел, колхозчы Альмир Сафиуллин, мәктәп хезмәткәрләре Рәмзия Галимова, Раилә Галиуллина язмышында да истәлекле көн бүген.

Референдумда катнашучыларның күбесе бина бусагасын атлап керүгә үз фикерен белдерә.

—Бары Союз яклы,—ди сугыш ветераны Нәкыя апа Вәлиева.—Ил иминлеген яклаганда иңгә-иң куеп көрәштек, хәрәбәләрдән илне бергә торгыздык. Хәзерге тыныч тормышыбызны да бары бергәләп кенә алга җибәрергә була.

Пенсионер Галия Хисамова һәм башкалар да аның фикеренә кушылалар.

Үз бурычларын үтәгән авыл кешеләре культура йортына юнәләләр —биредә алар өчен концерт, кино күрсәтелә. 6 җигүле ат өлкәннәрне, күрше Рус Морасасы авылы кешеләрен ташый, автобус та авыл белән Көрнәле Әмзә, Рус Морасасы авыллары арасын урый.

Шулай итеп, әлеге участокка теркәлгән 681 кешенең һәммәсе Союз язмышына карата бердәм булып үз фикерләрен белдерделәр.

Ф. СӘГЫЙРОВА,
участок комиссиясе рәисе.

Фикер уртак

Зирекле мәктәбе бинасына урнашкан СССР референдумын үткәрү комиссиясе каршына иң беренчеләрдән булып терлекче Галимҗан Зыятдинович Якупов килде.

—Мин бердәм Союзны яклап тавыш бирәм,—диде ул. —Моңарчы бергә яшәдек, моннан ары да бергә гомер кичерергә насыйп итсен.

Галимҗан Зыятдиновичның аягы җиңел булды, ярты сәгать эчендә зирекләләрнең 50 ләп кешесе ил язмышына карата үз мөнәсәбәтләрен белдерергә өлгерделәр инде. Аларның күбесе «Союзга—әйе» фикерен яклап тавыш бирүен яшермәде. Сәгать 11 гә тавыш бирүчеләр саны 286 га җитте. Үз аягы белән килә алмаган өлкәннәр, авыруларны атлар белән алып килделәр. Һәм менә 13 сәгать 10 минут референдумны үткәрү комиссиясе рәисе Р. Р. Хәмзин соңгы кешегә бюллетень бирә. Шулай итеп, 309 кешенең һәммәсе участокта булып, үз гражданлык бурычларын үтәделәр. Яңартылган Союз яклы—зирекләләрнең бердәм фикере шуннан гыйбарәт иде.

И. ШӘЙХИЕВ,
колхозның партоешма секретаре.

Милләтләр төрле, теләкләр бер

Кызыл Юл участогына теркәлгән 238 граждан арасында саный китсәң 7—8 милләт кешесе бардыр. Әмма Союз ныклыгы турында сүз барганда моннан да бердәм, моннан да уртак фикернең булуы да мөмкин түгел—һәммәсе яңартылган бердәм Союз өчен тавыш бирде.

—Бары шундый шартларда гына милләтләр дуслыгы, илебез иминлеге турында сүз алып барырга мөмкин,—диләр алар.

Референдум үткәрүне урман пункты администрациясе бәйрәм рәвешендә оештыру өчен күп көч куйган. Бу көнне ашханә, буфет, кибетләр эшләп торды, эшчеләргә ит сатылды. Күрше Чурабатыр авылыннан тавыш бирергә килүчеләрне машина ташып торды.

Сәгать 4кә СССР референдумында катнашырга тиешле халыкның 98 проценты тавыш биргән иде инде.

Ә. МӘХМҮТОВ.

Күбесе Союз яклы

17 март. Иртә. СССР референдумын үткәрү буенча Киекле участогы үзенең беренче сайлаучыларын көтә. Менә алар килә дә башладылар. Ничек тавыш бирерләр—әйеме, юкмы? Терлекче Вахит Вәлиәхмәтов һәм Талип Билаловның фикере бер—яңартылган тигез хокуклы Союз яклы. Аларның ил язмышына мөнәсәбәтен белдергән беренче бюллетеньнәре урнага төшә. Хәерле сәгатьтә!

... Кич. Референдум үткәрү комиссиясе нәтиҗәләреннән күренгәнчә, участок гражданнарының 98 проценты ССР Союзын яклап тавыш биргән.

В. АБДУЛЛИН.

Шартына туры китереп

ЯҢА ӘМЗӘ АВЫЛЫ. Референдумны үткәрү буенча комиссия Гомәр Габбасович Гайнетдинов, Сания Кирамовна Фәссахова кебек грамоталы, тәҗрибәле кешеләрдән тора иде. Шуңадыр да тавыш бирү барлык шартларына туры китереп үткәрелде, авыл кешеләре өчен үз фикерләрен яшермичә әйтү мөмкинлеге тудырылды.

С. ӘХМӘТҖАНОВ.

ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ:

„Татарстан“ колхозы савучысы Әкълимә Миндубаева.

Әкълимә Мәҗитовна узган ел колхоз сыер савучылары арасында социалистик ярышта беренче урынны яулаган иде. Аның быел да сынатырга исәбе юк. Ул үзенә тапшырылган маллардан продукция алуны киметмәс өчен бар тырышлыгын куеп эшли. Бүген ул һәр сыердан уртача 10,9 килограмм сөт сава. Бу Әкълимә Мәҗитовнаны канәгатьләндерми, билгеле. Тырышканда, малларны яхшы караганда, ашатканда уңышка ирешәчәген яхшы белә ул.

Җиңүчеләр ачыкланды

Район колхоз-совхозлары арасында февраль аенда сөт җитештерү буенча социалистик ярыш йомгаклары каралды. Һәр сыердан бу айда 271 килограмм сөт савып алуны тәэмин иткән «Заря» колхозы сөт җитештерүдә иң югары күрсәткечкә ирешкән өчен җәелдерелгән социалистик ярышта җиңүче исемен яулады. Һәр сыердан сөт савуны үткән елгы дәрәҗәдән арттыру өчен барган ярышта кабат «Үрнәк» колхозы җиңеп чыкты. Бу хуҗалык терлекчеләре февраль аенда һәр сыердан сөт савуны былтыргы шул чордагыдан 20 килограммга арттыруга ирештеләр.

Семинар үтте

Шушы көннәрдә Норлат сөт-май заводы каршында Октябрь районының товарлыклы-сөтчелек фермалары зоотехниклары, лаборантлары катнашында семинар үткәрелде.

Районда авыл хуҗалыгы продуктларын сатып алу һәм аларның сыйфаты буенча дәүләт инспекторы А. П. Белякова биредә катнашучыларны 1990 елда һәм 1991 елның ике аенда сөтнең сыйфаты, сөтчелек лабораторияләрендә сөтне исәпкә алу, аның сыйфат күрсәткечләрен билгеләү, товарны сөт-май комбинатына озатканда документларны рәсмиләштерү белән таныштырды.

Зоотехниклар һәм лаборантлар сөтнең сыйфатын билгеләргә, редуктаз сынавы үткәрергә, реактивларның стандартлыгын тикшерергә һәм башкаларны өйрәнделәр.

XXI партсъезд исемендәге колхозның сөтчелек фермасы лаборанты Г. Г. Гатин үзенең эш тәҗрибәсе белән уртаклашты. Шунда ук зоотехниклар һәм лаборантларны аттестацияләү үткәрелде.

Уртак фикергә килеп

13 март көнне «Кондырча» колхозында отчет җыелышы үтте. Хуҗалыкның узган елдагы эшләре турында отчетны анын рәисе С. М. Ильмухин ясады. Доклад Кондырча» колхозының үткән елдагы эшенә җентекле анализ рәвешендә иде, анда бүгенге күрсәткечләр белән бергә киләчәккә планнар да конкрет, төгәл билгеләнде. Хуҗалык елны начар тәгәлләмәде. Узган ел биредә бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культураларның һәр гектарыннан 30,7 центнер, чөгендердән 289 центнер уңыш үстерелде, һәр сыердан 3711 килограмм сөт савылды. Докладчы бу уңышларның нигезе булган колхоз уңганнарының исемен зур горурлык белән атады. Шул ук вакытта киләчәктә дуңгызчылык белән шөгыльләнү кирәклеген дә ассызыклады. Шунсыз хуҗалык быелгы кебек ук ит җитештерү һәм сату планын үти алмаячак. Бу фикерне чыгыш ясаучылардан ферма мөдире Я. И. Таҗиев та куәтләде.

Гомумән, фикер алышулар бик төпле, җанлы барды. Колхозның баш агрономы А. Ш. Бикиниев киләчәктә агротехник чараларны үзвакытында үткәрү кирәклеген ассызыклады. Баш инженер Р. Н. Мәүлетов техника паркының торышын анализлады, башкару дисциплинасына тукталды. Киләчәктә җылы гараж төзүне тизләтү кирәклеген әйтеп үтте. Колхозның тәҗрибәле механизаторы В. Тәмаев колхоз эшчәннәрен бердәм хезмәткә чакырды. Кырчылыкта аренда звенолары җитәкчеләре М. Бакиров һәм С. Гомәров та нигездә шул фикерне куәтләделәр. Чын аренда һәркем намуслы, тигез хезмәт куйганда гына була, диделәр алар.

Җыелышта Кормыш авыл Советы рәисе В. Х. Шәйхетдиновның авылны социаль үзгәртеп кору, мәктәп директоры М. Х. Хисмәтуллинның мәктәп төзелеше һәм авыл хуҗалыгы кадрларын хәзерләүдә мәктәпнең роле турында чыгышлары да игътибар белән тыңланды.

Колхоз киләчәктә дә бүгенге үрләрдән чикмәс өчен кулга-кул тотышып, бердәм булып эшләргә тиеш —җыелышта катнашучылар әнә шундый фикер белән таралыштылар.

Х. ФӘТХУЛЛИН.

Түгәрәк өстәл артында сөйләшү

12 март көнне КПСС райкомы бинасында «Татарстан» журналы редакторы урынбасары В. И. Пискарев, редакциянең иҗтимагый-политик тормыш бүлеге мөдире Т. Ф. Морозова катнашында түгәрәк өстәл артында сөйләшү булды. Хәзерге этапта башлангыч партия оешмаларының роле турында ачыктан-ачык сөйләшүдә КПСС райкомы аппараты работниклары, бер төркем район хуҗалыклары, оешма-предприятиеләр партоешма секретарьлары, район Советы башкарма комитеты, сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, ВЛКСМ райкомы вәкилләре, колхоз рәисләре катнашты.

Шәхси мәнфәгатьләр өстен чыкса...

Күптән түгел республика ветераннар советы президиумы утырышы булып үтте. Анда чыгыш ясаган иптәшләрнең күпчелеге РСФСР Югары Советы рәисе Б. Н. Ельцинның чыгышына тукталып узды. Аны тәнкыйтьләүче, акларга тырышучылар да табылды. Мин дә дәшми кала алмадым, сүз сорадым, чөнки күңелемә, кем әйтмешли, төер шактый һәм күптәннән җыела килә иде.

Хәер, аңа кадәр кереш рәвешендә бер нәрсәне ачыклап үтик. Үзгәртеп корулар илебездә демократияне, хәбәрдарлыкны җәелдерүгә этәргеч булды. Б. Н. Ельцин да союз күләмендә шул чорда мәгълүмлелек алган лидер. КПСС Үзәк Комитетының октябрь (1987 ел) Пленумындагы чыгышы, аннан соңгы вакыйгалар аның рейтингын күпкә күтәреп җибәрде. Ул чактагы чыгышының бәян ителмәве, коммунистлар, халык өчен сер булып калуы аның файдасына булды. Халык аны демократия яклы, шуңа күрә югары ранг җитәкчеләр тарафыннан эзәрлекләнгән кеше итеп кабул итте, аңа өметләрен баглады.

Ул чорда, сер түгел, аның күп фикерләре белән күңелдән килешә, гаделлек аның ягында тоела иде. Халык арасында да шул сәбәпле тарафдарлары күп иде. Демократик лозунгларны оста һәм еш кулланып ул РСФСР Югары Советы рәисе итеп сайлануга ирешә.

Әмма ул яңа төр политик лидер буларак күп сайлаучыларның һәм хезмәт ияләренең ышанычын акламады. Мин үзем дә аңа булган ихтирамымны югалттым. Моның сәбәпләрен ачыклап үтүне кирәк саныйм.

Борис Николаевичның АКШка депутат буларак сәяхәте турындагы документаль фильм заманында халык арасында күп бәхәсле фикерләр тудырды. Чыгыш ясаган аудитория алдында үз-үзен тотышы америкалыларга да ышамагандыр дип уйлыйм, илебез тамашачылары алдында да шөһрәт өстәмәде.

Яки аңа һөҗүм оештыру турында хәбәр таратуын алыйк. Булганмы, юкмы —безнең өчен билгесез калды, чөнки ул үзе бу мәсьәләне тикшерүне азагынача җиткертүдән баш тартты.

Без, гадәттә чиктән чиккә ташланырга гадәтләнгән, бер тәнкыйтькә алынсак кешене гел кара күзлектән чыгып кына бәялибез. Моны шуның өчен әйтүем, Борис Николаевич ил җитәкчеләре белән бәхәскә кергәч, аны гел тискәре яктан гына күрсәтү, хаталарын эзләү башланды. Кызганычка каршы, бу нәкъ кире тәэсир ясады, аның файдасына хезмәт итте.

Рәсми чыгышларында Борис Николаевич, алда әйткәнемчә, демократия тарафдары буларак популярлык казанды. Әмма Россия Федерациясендә Югары постны биләп алгач, бик тиз һәм кискен борылыш ясады. Союз күләмендә мәгълүм кешегә ул КПСС члены буларак әверелде. Әмма партиягә тәнкыйть ябырылгач, катлаулы һәм кыен моментта аны бик ансат һәм демонстратив рәвештә ташлап чыкты.

*

Властька килүенең беренче көннәреннән үк ул Союз хөкүмәтенә, СССР Югары Советына каршы көрәш җәелдерде. Аның тырышлыгы белән илдә законнар көрәше башланды. Бу, хәлбуки, илдәге болай да киеренке хәлне аеруча катлауландырды.

Балтыйк буе республикалары халкына мөнәсәбәт күңелдә аңа булган ихтирамның соңгы өлешен дә юып ташлады. Бу республикаларның җитәкчеләре союздан аерылып чыгу, үзләрендә капиталистик мөнәсәбәтләрне яңадан торгызу чараларын күрә башладылар. Бу республикаларда кабул ителгән яңа законнар нигезендә азчылык халык—руслар, поляклар, белоруслар һәм башкалар икенче сорт кеше итеп карала. Һәм Борис Николаевич аларның бу политик курсын яклап чыкты. Шушы демократия, тигезлек, гаделлек буламы?

Татарстан суверенлык хокукын яулаганда да ирекне теләгән кадәр алыгыз дип белдергән иде. Әмма чынбарлыкта бу мәсьәләдә дә тәртәне тиз борды, республиканы һаман Россия составында тоту курсын гамәлгә ашыра. Россиядә аерым армия төзү турында белдерү дә төптән уйлап әйтелгән фикер димәс идем. СССР Президентының җинаятьләрне кисәтүгә юнәлдерелгән милиция һәм хәрбиләрнең бергәләп патрульлеген оештыру турындагы Указына да каршы чыкты.

Телевидение буенча соңгы интервьюсы исә Ельцинның шәхси мәнфәгатьләре турында кайгыртып, Союз хөкүмәтенә каршы чыгуы Президентның илдә шундый киеренке хәл чагында отставкасын таләп итүе чама чиген бөтенләй онытуы турында сөйли. Властьны федерацияләр советына тапшыру илнең таркалуы дигән сүз. Борис Николаевич моны үзе властька омтылудан чыгып бәян иткәнлеген чамалавы кыен түгел.

Һәм, хакыйкатьне әйтергә кирәк, бу чыгышы элек аңа ышанган күп хезмәттәшләре арасында да кискен фикер каршылыклары, аның эшчәнлегеннән ризасызлык уятты. 28 мартта РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездын чакыруга да шул сәбәп булды.

Балык башыннан чери, ди халык. Җитәкче кеше шәхси ихтыяҗлардан бигрәк халык, ил мәнфәгатьләре турында кайгыртырга тиеш. Минем фикеремчә, Борис Николаевичка соңгысы җитешми, амбициясе, югары дәрәҗә, властька омтылышы иҗтимагый интересларын күмеп китә. Мондый сыйфатлар кешене бизәми, җәмгыять өчен дә зарарлы, тоталитар режимга китерә. Безнең тарихыбыз мондый фактларга бай инде. Борис Николаевич та демократия турында сөйләп, үзен шул система яклы кеше итеп күрсәтте. Һәм шуның белән үзенә булган ихтирамның күп өлешен югалтты.

И. ПЕТРОВ,
сугыш һәм хезмәт ветераннарының район советы рәисе.

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

Кызыклы тамаша

Мәктәбебездә «Ягез әле, егетләр!» дигән тамаша үткәрергә булдык. Сәгать 10 га барыбыз да җыелып беткән идек инде һәм ярышлар башланып китте. Кызыклы конкурсларның төрлелеге зур иде. Мәсәлән, чиләккә туп кертү, күз бәйләп йорт рәсеме ясау: беренче түбәсен, икенчесе стеналарын, өченчесе ишек, тәрәзә ясый. Бәрәңге чистарту конкурсы алдыннан алъяпкыч һәм яулык бәйләү сорала. Егетләребез ашыгу сәбәпле, алъяпкычларын, яулыкларын ничек теләсәләр шулай бәйләп куйдылар. Һәркемнең үзенчә. Кызларыбыз чын күңелдән көлеп җавап бирделәр моңа. Тагын бер ярыш кызыклы иде: син өйдә алты яшьлек сеңелең белән калгансың һәм аңа бант бәйләп, әкият сөйләргә тиешсең, ди. Сеңел роле миңа тиде. Ләкин бант бәйләү эше ир-атка бер дә йогышлы түгел. Шуңа бант килбәтсез чыкты, шулай да ничек җитте шулай бәйләделәр.

Тамаша бик кызыклы булды. Уен-көлке кичә буена дәвам итте, безнең егетләр икенче урынга чыктылар. Хәзер без «Әйдәгез әле, кызлар!» ярышына хәзерләнәбез.

Л. ЧЕРКАСОВА,
4 нче мәктәпнең яшь хәбәрчеләр түгәрәге члены.

Туган як тарихын өйрәнәбез

Безнең 4 нче урта мәктәп укучылары туган як тарихын яратып өйрәнәләр. Укытучыбыз Вил Сергеевич Пимурзин дәресләрне кызыклы итеп үткәрә. Без мәктәпкә сугыш һәм хезмәт ветераннарын чакырабыз. Алар безгә үзләре күргәннәр, яшьлек еллары турында кызыклы итеп сөйлиләр.

Күптән түгел шәһәребезнең музыка сөючеләре булды мәктәптә. Сәгыйть бабай Гобәйдуллин үзенең зур һәм кечкенә гармуннарын алып килгән иде. Ул бик матур итеп уйнады, ә Рамил Мифтахов җырлап ачты күңелләрне. Без аларга чиксез рәхмәтләребезне җиткердек, тагын килүләрен сорадык.

Л. АЛИЕВА,
10а класс укучысы.

ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: Мичурин исемендәге колхоз чөгендерчесе Зинаида Филипповна Кульметьева. Колхозның бер төркем хатын-кызлары белән бергә озак еллар чөгендер плантацияләрендә эшли ул. Узган ел үз участогында 318 әр центнер уңыш үстерде. Хәзер Зинаида Филипповна наряд буенча төрле эшкә йөри. Хуҗалык җитәкчеләре беләләр: кая кушсалар да ул үз хезмәтен намус белән башкара.

Бу безгә—тереләргә кирәк

Бүген илебездә сугышчы-интернационалистлар язмышына битараф кешеләр юктыр. Ерак Әфган җиреннән килгән хәбәрләрне аналар, туганнары ничек өзелеп көтеп алалар иде бит. 1989 елның 15 февралендә совет гаскәрләренең соңгы группасы туган җиребезгә аяк басты. Әфганстанда хезмәт итүчеләр арасында районыбыз егетләре дә күп. Алар хәзер безнең арабызда, хезмәт коллективларында ата-бабаларының эшен лаеклы дәвам иттерүчеләр.

Әле соңгы мәктәп кичәсендә яңгыраган музыка тавышларын да онытып җиткермәгән малайларны ут эченә кертү кызганыч, ләкин кирәк!

Безнең совет солдаты һәрвакыт интернационалист булды. Без әфган халкының ирек өчен башларын салган сугышчыларыбызны һәрвакыт күңелдә сакларга тиешбез. Без аларның батырлыгы алдында баш иябез. Тирән кайгы белән хәтергә алабыз.

«Интернационалист» клубы советы чакыруына җавап итеп якташларыбыз—сугышчы-интернационалистлар өчен төзелгән һәйкәл исәбенә 700902ле счетка акча күчерүчеләргә рәхмәтебезне белдерәбез.

Бу башлангычны шәһәребезнең оешмалары, хуҗалыклары гына түгел, ә кайбер иптәшләребез дә яклап чыкты: сөт-май заводы лаборанты В. Г. Захарова балаларының беренче айлык пособиесен 35 сум күләмендә бу счетка күчерде.

Бүгенге көндә 700902 номерлы счетка «Восход», «Большевик», Мичурин исемендәге, «Татарстан», «Игенче», XXI партсъезд исемендәге колхозлар һәм «Төрнәс» совхозы үз өлешләрен керттеләр. Кемнәр әле үз өлешләрен кертергә өлгермәгәннәр, ашыгыгыз. Якташларыбызның исемнәрен мәңгеләштерүдә читтә калмыйк. Безнең бурыч—аларның якты хатирәсен саклау. Бу безгә—тереләргә кирәк.

Р. ӘХСӘНОВА,
ВЛКСМның район комитеты секретаре.

Кыскача

Төркиянең 800 мең гаскәриле кораллы көчләре АКШтан кала НАТОда икенче урында тора. Шул ук вакытта Төркия армиясе искергән хәрби техникага бик нык бәйле. Фарсы култыгындагы сугыш тәэсирендә хөкүмәт һәм хәрбиләр америкалылар үрнәгендә профессиональ кораллы көчләр булдырырга ниятли.

Сорагыз—җавап бирәбез

«Аукционнар ничек оештырыла һәм үткәрелә, аннан кергән акча кая тотыла, мөмкин булса шуны аңлатсагыз иде?».

М. САФИНА,
Нурлат шәһәре.

Аукцион үткәрү өчен бүленгән торган саклы әгъзалар кертелгән махсус комиссия төзелә. Биредә бәяләр буенча экономист, өлкән товар белгече, райисполкомнан вәкил, райпо җитәкчелегеннән кеше һәм башкалар.

Тәкъдим ителә торган товарлар исеме билгеләнә. Махсус исемлек төзелә һәм биредә түбәндәгеләр күрсәтелә: товарның беренчел бәясе, аның старт бәясе (аукционда катнашучыларга тәкъдим ителә торганы), ә сатудан соң аның бәясе куела. Моннан тыш, әрерәк әйберләр алучыларның адреслары языла һәм аларның куллары куела.

Аукционнан кергән акча шәһәр үсеше өчен тотыла, ә 20 проценты оештыру мәсьәләләрен хәл итүгә китә.

Аукцион үткәрү район финанс бүлеге контролендә тора.

Т. ИЛЯЛОВА,
Дәүләт сәүдәсе һәм кулланучылар кооперациясе профсоюзының район комитеты председателе.

—Карусыз, тырыш шофер. Бер дигән гаилә башлыгы,—диделәр Солтан Хөснуллов турында.

Солтан Хөснуллов 30 ел берөзлексез шофер булып эшли. Күп еллар буена колхозда төрле йөкләр ташыган, ә 10 елдан артык инде иң кыйммәтле йөк— сөт ташый ул. Аңа җәй көннәрендә сөт-май комбинатына ике рейс ясарга туры килә. Һәм бу вакыт эчендә аның гаебе белән сөтнең бозылуына юл куелганы юк. Ул теләсә нинди һава шартларында да сөтне вакытында илтеп җиткерә. Алдынгы шоферның фоторәсеме берничә ел рәттән хуҗалыкның Мактау тактасында торды, исеме районның Мактау кенәгәсендә булды.

Солтан Хөснуллов 1990 елны да матур нәтиҗәләргә ирешеп тәмамлады. Аңа киләчәктә дә уңышлар телисе килә.

Рәсемдә: «40 лет Победы» колхозы шоферы С. Хөснуллов.

В. Никонорова фотосы.

КОЛЛЕКТИВ НЫГЫЙ

Дәүләтша Фәйзрахманович, дуңгыз фермасына мөдир итеп барырга тәкъдим иткәч, башта чынчынлап уйга калды. Терлекчелектә яңа кеше түгел ул, күрсәткечләрне яхшыртуның ни бәягә төшәчәген әйбәт чамалый. 10 ел товарлыклы-сөтчелек фермасын җитәкләгән кеше ни әйтсәң дә. Дуңгызчылыкта да шуннан җиңелдән булмаячак. Әлегә күрсәткечләр әлләни түгел, коллектив та таркау гына. Нишләргә?

Шул тынгысызлыгы җиңде фикер көрәшендә: узган елның январь аенда фермага мөдир булып килде. Менә бер ел үтте, мөдир саннарны чагыштыра: январь аенда дуңгызлардан тәүлеклек артым алу 349 грамм тәшкил иткән. Соңгы балалатуда һәр төп ана дуңгыздан 9 га якын бала алынган.

Дәүләтша Фәйзерахманович җылы, коры, якты балалату бинасына кергән саен шатланып чыга. Тере, ап-алсу, түм-түгәрәк дуңгыз балалары үсәм, булам дип торалар, сөбханалла. Биредә күпме көч куелганын аннан да күп белүче колхозда да юктыр. Эшкә керешкән көннәренең баштагы мәленнән күз алдыннан үткәрә башласаң...

Нәрсәдән башладылармы? Иң элек коллектив белән ачыктан-ачык сөйләшүдән. Тема бар, сүз күп җыелган иде. Шул ук дисциплина, чисталык, корылык, даими җылылык һәм зооветталәпләрне үтәү. Дәүләтша ага киләчәктә боларның һичшиксез үтәлергә тиешле нәрсәләр булуын коллективка беренче сөйләшүдә үк аңлатырга тырышты. Әлбәттә, эш дәвамында бу мәсьәләләргә кабат-кабат әйләнеп кайтырга туры килде килүен, контроль әле хәзер дә кирәк. Әмма беренче сөйләшү барыбер күп нәрсәне хәл итте. Аннан ары инде продукция җитештерүнең технологик нечкәлекләрен акрынлап төшендерә башлады. Дежурлыкны ныгытты, кечкенә генә нәрсәләрнең дә тармак бөтенлеге өчен мөһим булуын аңлатырга тырышты. Әйтик, ана дуңгызлар балалаган чорда су куюга игътибар булмаган— аны төзәттеләр. Үлем-китемгә юл куймау максатында, аналарны яшь үрчемнән аерым асрарга булдылар. Җылылык җитсен өчен кварц лампочкалары элделәр. Бусын «Рассвет» совхозыннан семинардан кайткач эшләделәр. Дәүләтша абзый, гомумән, урыннарда үткәрелә торган шундый семинарларны бик файдалы итеп саный. Хезмәткә натураль түләү мәсьәләсен дә шуннан соң җайга салдылар бит. Хәзер һәр балалатудан 6,5 дуңгыз баласы колхозга тапшырылырга тиеш, шуннан калганы—дуңгыз караучы ихтыярында. Ул аны я үзенә ала, я үстереп килограммын 2 сумнан колхозга сата. Әйтергә кирәк, бу яңача эшләүнең файдасы аерата күп булырга күренә. Соңгы балалатуда 8,8 баш үрчем алу—бу бит зур нәрсә.

Хәер, коллективның эшләү кәефе, теләге үк күзгә күренеп үзгәрде. Ә ул тырыш, булдыклы хатыннардан тора. Әнә Зоя Евдокимова, мәсәлән. Бу тармакта 20 еллап эшли инде ул, технологияне белә, һәр эшне җиренә, ноктасына җиткереп эшли. Узган ел ул ел әйләнәсенә 400 граммнан да ким артым алмады. Январьда аны 500 гә җиткерде. Игътибарлы, гаҗәеп эшчән хатын. Шуңа да аның исеме районның иң алдынгы дуңгыз караучылар белән рәттән әйтелә. Хәзер ул ремонт аналарны карый, каплату эшләре уңышлы үтәлде, инде балалатуга да үзе алып керә.

Раиса Павлова белән Раиса Юхмальчина да шундый ук мактауга лаеклар, Раиса Бураева исәнлеге борчыса да алардан калышмый. Хәер, фермада эшләүче бер хатын-кыз да исәнлеге белән әлләни мактана алмыйдыр ул. Бигрәк авыр хезмәт бит. Кайчак аларны кызганып та куя Дәүләтша ага. Иртәнге 4тән тотына апайларның эш көне, кичке 8 гә кадәр сузыла. Ялы да, бәйрәме дә юк. Бөтен эш диярлек кулдан башкарыла. Боткасы, печән оны, аертылган, яшь балаларга куе сөте—һәммәсе алар кулы аша уза бит. Соңгысын имезлек белән бирәләр әле. Нәкъ менә яшь бала караган кебек инде, билләһи. Баштагы мәлдә, үрчем яшьрәк вакытта, аерата тынгысызга килә. Әмма шулай итмичә булмый, шундый хезмәт куйганда гына уңышка ирешеп була.

Бу җәһәттән ферма эшчәннәренең бер омтылышта, бер сүздә булуы шарт. Дәүләтша Фәйзрахманович терлекчеләр Николай Максимов һәм Фоат Хуҗахановның да шуны аңлап эшләвен күрә. Аларга хезмәт дисциплинасы, тәртип турында искәртеп торуның кирәге юк.

Өстәмә нарядсыз да алар үз вазифаларын бер дигән итеп башкаралар, дуңгыз караучылар белән уртак тел табып эшлиләр.

Тагы бер кешенең хезмәте мактауга лаек биредә. Ул—ягучы Николай Константинович Васильев. Элек бу эшне 2 кеше башкара иде, хәзер ул берүзе өлгерә. Бер яктан акчасы үссә, икенче яктан эшче кулларга кытлык икәнлеген дә онытмыйк. Ә җылылык бар, ул даими һәм ул— Николай Константиновичның тырыш хезмәт нәтиҗәсе.

Быел хуҗалык өчен җиңел ел түгел. Терлекләргә ашатырга фураж кытлыгы туды, әле аннан, әле моннан җыеп, малларны аннан өзмәскә тырышалар. Киләсе җәйдә имезүдән аертылган группалар асраласы бинаны җылыту турында да уйларга кирәк булачак. Болар һичшиксез эшләнер. Чөнки тармак, хуҗалык җитәкчеләрен сөендереп, күзгә күренеп ныгый, үсә.

Димәк, Дәүләтша Фәйзрахманович Мостафин тикмәгә генә алынмаган мөдирлек эшенә.

С. ХӘЙРУЛЛИНА.

«Родина» колхозы.

ГАЗЕТАГА БАСЫЛМАСА ДА...

Төпле җавап көтеп

Редакция Бутаиха поселогында яшәүчеләрдән борчулы хат алды. «Менә бер ел була инде клубыбызда кино булганы юк. Клуб мөдиренең моңа исе дә китми. Ә күптән түгел китапханәче һәм клуб мөдиренең эш хакларын арттырдылар. Ә нәрсә өчен? Бинаны саклап яткан өченме?»—дип язалар алар.

Бу хатны район Советы башкарма комитетының культура бүлеге мөдире Р. Х. Морадыймовка җибәрдек. Әмма җавапны бары тик район үзәк китапханәсеннән алдык.

Үзәк китапханә директоры О. М. Венидиктова үзенә кагылышлы сорауга тулы җавап биргән. «Китапханәчеләргә хезмәт хакын бөтенсоюз буенча арттырдылар. Ә Бутаиха авыл китапханәсе мөдиренең айлык хезмәт хакы 140 сум. Чөнки аның махсус белеме дә, эштә зур уңышларга ирешә алганы юк»,—дигән юллар бар аның җавабында.

Сезгә дөрес түләнгән

Редакциягә XXI партсъезд исемендәге колхоз сыер савучысы Флера Исхаковна Вәлиевадан кергән хатта мондый юллар бар иде:

«Хөрмәтле редакция. Бәхетсезлек буенча страхование ничек түләнә? Сыер тибеп кулым, аягым сынган иде. Больницада дәваландым. Үзем бәхетсезлек очрагына страхование түлим. Ә миңа бәхетсезлек очрагы буенча 50 сум акча түләделәр. Бу шулай дөресме?».

Хат тикшереп җавап бирү өчен Дәүләт страхованиесенең район инспекциясе начальнигы Р. ВӘЛИУЛЛИНга юлланган иде. Аннан редакциягә түбәндәге җавап алынды: «Сез бәхетсезлек очрагына 1000 сумга страховой договор төзегән булгансыз. Сезгә 5 процент яки 50 сум түләнгән.

Без түләүне сез дәваланган Әлмәт участок больницасы биргән 195 формасы белгечләмәсе буенча үткәрдек. Сез хатта кулыгыз сыну турында да әйткән идегез. Ә медицина белешмәсендә башка травма турында күрсәтелмәгән. Димәк, сезгә страховой сумма дөрес түләнгән».

Кырлар сый ала

«Агропромхимия» берләшмәсенең бер отряды безнең «Рассвет» совхозында эшли. Аңа элек-электән игенчелек белән шөгыльләнгән Х. Яһудин җитәкчелек итә. Бригада бик әйбәт хәзерлекле механизаторлардан тупланган. Узган көз алар совхозның 1700 гектар эче туфраклы җирләрен известьлаганнар иде инде. Ә хәзер алар басуга ашлама ташыйлар.

Совхоз җитәкчелеге дә аларга һәрьяклы ярдәмен итә. Бригадага ике бульдозер беркеттеләр. Баш агрономыбыз Н. Мусин бу эшнең бөтен җаваплылыгын тоеп уңыш өчен көчен кызганмый. Бригада членнары Т. Таҗиев, И. Курамшин, К. Вәлиев, Ф. Ильмухин, С. Гаврилов, С. Кәримов, Ш. Хәсәнҗанов көнлек нормаларын 120—130 процентка үтиләр.

Совхозыбыз игеннары үткән ел бөртеклеләрдән гектарына уртача 31 центнер уңыш җыеп алды. Бу җирне тәрбияләүгә әһәмият бирү нәтиҗәсе.

Т. ГОБӘЙДУЛЛИН.



Рәсемдә: «Комбайн» колхозының алдынгы савучылары Әкълимә Әнвәровна Йосыпова, Әлфия Гомәровна Хуҗина һәм Зәйтүнә Хәсәнҗановна Гайсина. Аларның өчесе дә узган ел нәтиҗәләре буенча колхозда иң алдынгы урыннарны алып торалар. Хәзер дә алар группасында көнлек савым 11—12 килограмм тәшкил итә.

Н. Азизов фотосы.

Машиналарга җан өрә

Камил Галиуллович Хөснуллинны «Безнең машиналарның йөрәге» диләр Хафизов исемендәге колхозда. Монда хаклык зур. 1953 елдан бирле элеккеге «Дружба» колхозында 21 ел буе тракторчы, комбайнчы булып эшләгән ул. Аннан аны хуҗалык автопаркына слесарь-моторчы итеп алдылар. Менә 16 ел инде ул үз хезмәте белән машиналар йөрәгенә «җан өрә»—җиңел һәм йөк машиналары моторларына ремонт ясый. Әгәр запас частьләр белән тоткарлык булмаса, ай саен 3әр мотор ясарга өлгерә ул. Моның өчен нинди тәгаллек, техник осталык, сәләт кирәк, Камил Галиуллович нәкъ шундый сыйфатларга ия дә. Шуңа да аның янына еш кына күрше хуҗалыклардан да ярдәм сорап киләләр. Ә тәҗрибәле оста аларның берсен дә кире бормый, йомышларын үтәргә, гозерләрен тыңларга вакыт таба. Шуңа да хезмәттәшләре аның турында иң әйбәт фикердә торалар. Хәер, Хөснуллиннар гаиләсе гомумән бик уңган, тырыш гаилә буларак мәгълүм авылда. Камилнең хатыны Гөлсәрия кышын бригадада төрле эштә йөри, җәй көннәрендә чөгендер алыны алып эшкәртә. Узган җәйне дә ул эшләгән звено һәр гектардан 257 шәр центнер яхшы сыйфатлы татлы тамыр җыеп тапшырды.

Шулай намуслы хезмәттә үтә Хөснуллиннарның тормышы, Камил Галиуллович тырышлыгы, булдыклылыгы белән күп техниканың гомерен озайта, күп машиналарны сафка кайтара. Шуңа да «Безнең машиналарның йөрәге» дип бик дөрес әйтәләр хафизовлылар аның турында.

Т. ДЕРБЫШЕВ,
хәбәрче.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ

СИШӘМБЕ
19 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.25 «Диалоглар». ТССР Дәүләт гимнының иң яхшы проектына конкурс.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Нәтиҗә». Тапшыруда халык депутатларының Апас район Советы рәисе Ә. Н. Хәйруллов катнаша.
20.00 Әлли-бәлли-бәү.
20.10 Н. Җиһанов истәлегенә әдәби-музыкаль кичә.

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00 «Актуаль репортаж».
9.15 Нәфис фильм: «Әх, бу җүнсез, җүнсез телевизор».
10.50 Балалар сәгате (француз теле дәресе белән).
12.15 «Туган күкнең гүзәл яктылыгы».
15.15 Нәфис телефильм: «Тимер уеннар».
16.45 Балаларның музыка клубы.
17.30 «Шигърият минутлары». Владимир Нежданов.
17.35 «Әрнү һәм өмет». Телевизион очерк.
18.20 Хоккей. СССР чемпионаты. «Спартак»—ЦСКА. Тәнәфестә (19.05)—«Меридиан».
21.00 «Вакыт».
21.45 «ВИД» күрсәтә: «Могҗизалар кыры».
22.30 Профессионаллар арасында бокс буенча дөнья чемпионаты. Аеруча зур авырлыктагылар.
23.30 «Эстрада вернисажы».
00.40 Нәфис телефильм: «Кыз һәм диңгез».
02.10 «Чынлап та, шаяртып та». Киноконцерт.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Фәнни-популяр фильм.
8.35, 9.35 Физика. 11 класс.
9.05 Француз теле 1 нче уку елы.
10.05 Француз теле. 2 нче уку елы.
10.35, 11.35 География. 7 класс.
11.05 Сәламәтлек.
12.05 Нәфис фильм. «Уйлау өчен вакыт».
13.10 Музыкаль телеабонемент.
13.50 Язның биш минуты.
14.05 РСФСР шәһәрләре телестудияләре.
14.40 Ритмлы гимнастика.
17.00 К. Зидаров. Фильм-спектакль: «Патша мәрхәмәте».
18.30 Экология. Җәмгыять. Кеше.
19.45 Россиянең парламент хәбәрчесе.
20.00 «Тыныч йокы, нәниләр».
20.15 «Безнең мәшәкатьләр Джон Кристал күзлегеннән карагында». Авыл хуҗалыгы продукциясен саклау буенча бердәм эш.
20.30 Ритмлы гимнастика.
21.00 «Вакыт».
21.45 СССР Югары Советы сессиясендә.
22.45 Нәфис фильм. «Хатыным, балаларым минем».

ЧӘРШӘМБЕ
20 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.30 Нәфис фильм, «Фаш ителмәскә тиеш».
19.00 «Татарстан».
19.25 «Телесеанс». Яшьләр өчен тележурнал.
19.55 «Нәтиҗә». Кечкенә авыллар проблемасы. (Сарман районы).
20.25 Әлли-бәлли-бәү.
20.35 Рәссам Бронюс Грушас. (Вильнюс шәһәре).

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00 «Эшлекле курьер».
9.15 Мультфильм: «Кемнәр соң алар, кошчыклар».
9.35 Хоккей. СССР чемпионаты. «Спартак»—ЦСКА.
12.15 Профессионаллар арасында бокс буенча дөнья чемпионаты. Аеруча зур авырлыктагылар.
15.15 Күп серияле нәфис телефильм: «Михайло Ломоносов». 1 нче фильм. «Үз чыганакларыннан». 1 серия.
17.10 Балалар сәгате (инглиз теле дәресе белән).
18.10 «Үзгәртеп кору. Ул Япониядә ничек булды?». 2 нче тапшыру.
18.55 Футбол. УЕФА кубогы. 1/4 финал. «Торпедо» (Мәскәү)—«Брондью» (Дания).
21.00 «Вакыт».
21.45 «Керергә рөхсәт итегез». «Московский комсомолец» газетасы «Аваз сукмагы» лауреатлары концерты.
22.55 Футбол. Европа кубоклары. 1/4 финал.
00.50 Футбол. Кубок ияләре кубогына. 1/4 финал. «Барселона» (Испания)—«Динамо» (Киев). 2 нче тайм.
01.40 Нәфис телефильм: «Ярминкәдән соң».

II ПРОГРАММА

8.15 Фәнни-популяр фильм.
8.35, 9.35 Физика. 9 класс.
9.05 Немец теле. 1 нче уку елы.
10.05 Немец теле. 2 нче уку елы.
10.35, 11.40 Физика. 7 класс.
11.05 Адам Смит акчалары дөньясы.
12.10 Нәфис фильм. «Хатыным һәм балаларым минем».
13.20 «Объектив». Һәвәскәр фильмнарның Бөтенсоюз фестивале.
17.00 Телеспектакль премьерасы.
19.00 Документаль фильм. «Тупас эш».
19.25 «Кадерлем Валера». Язучы В. Некрасов турында.
19.55 Коллаж.
20.00 «Тыныч йокы, нәниләр!».
20.15 Ирма Худякованың ел фасыллары. Улан-Удэдан тапшыру.
20.50 Документаль фильм. «Алга, Аргамак». Йөгерешчеләр клубы турында. (Казан).
21.00 «Вакыт».
21.45 СССР Югары Советы сессиясендә.
22.45 РСФСР Югары Советы сессиясендә.

ПӘНҖЕШӘМБЕ
21 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.00 СССРның халык артисты Н. Җиһановның тууына 80 ел тулу уңаеннан тантаналы җыелыш һәм концерт. (Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрыннан трансляция). Тәнәфестә—«Татарстан».
21.00 «Диалог» турында диалог. Совет—Америка «Диалог» предприятиесенең барлыкка килүе һәм үсеше (Чаллы шәһәре).

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00 «МВД хәбәрләре буенча».
9.30 Футбол. Европа кубоклары.
12.15 Якут-Саха ССРның дәүләт бию ансамбле концерты.
15.15 «Һәвәскәрләр дөньясы».
15.30 Нәфис телефильм: «Михайло Ломоносов». 1 нче фильм. «Үз чыганакларыннан». 2 серия.
17.05 Балалар өчен фильм. «Карлар юлбарысы».
18.15 «Чемпионнар белән бергәләп».
18.30 «Меридиан».
18.45 «...16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәк».
19.15 Нәфис телефильм: «Ак каргалар».
21.00 «Вакыт».
21.45 «МВД» хәбәрләре буенча».
22.00 «Опера театры дөньясы».
23.00 «Пи» билгесе астында».
00.45 «Александр Вертинский: «Мин өемә кайттым».
02.15 Нәфис телефильм: «Сәгать ясаучы һәм тавык». 1 серия.

II ПРОГРАММА

8.15 Документаль фильм.
8.35, 9.35 Гомуми биология. 11 класс.
9.05 Испан теле. 1 нче уку елы.
10.05 Испан теле. 2 нче уку елы.
10.35, 11.35 Әдәбият. 10 класс.
11.05 «ТелеЭКО» журналы.
12.05 Питер Брук. Мәскәүдәге очрашулар.
13.35 Ирма Худякованың ел фасыллары. Улан-Удэдан тапшыру.
17.00 «Гаҗәп хәлләр, сәер хәлләр».
17.45 Документаль фильм. «Лев Яшин».
21.45 РСФСР Югары Советы сессиясендә.
23.15 Нәфис фильм. «Монмартр түбәсе астында». 1 һәм 2 нче серияләр.

ҖОМГА
22 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.00 «Җомга көн кич белән». Альманах.
19.00 «Татарстан».
19.30 Әлли-бәлли-бәү».
19.40 «Котлы булсын Нәүруз».

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00 Нәфис телефильм: «Ак каргалар».
10.45 Мультфильм.
11.35 «Мин сезне очраттым». Б. Медведев җырлый.
12.15 «Опера театры дөньясы».
13.15 «...16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәк».
15.15 «Һәвәсләр дөньясы».
15.30 Нәфис телефильм: «Михайло Ломоносов». 1 нче фильм. «Үз чыганакларыннан». 3 серия.
16.40 «Әни, әти һәм мин».
17.10 Мультфильм.
18.00 «Контакт-форум».
18.30 «Меридиан».
18.50 «ВИД» программасы.
19.05 Нәфис документаль фильм: «Гарольд Ллойд—өченче даһи». 1 һәм 2 серияләр.
21.00 «Вакыт».
21.45 «ВИД» программасы.
02.15 Нәфис телефильм: «Сәгать ясаучы һәм тавык». 2 серия.

II ПРОГРАММА

8.15 Документаль фильм.
8.45, 9.35 Безне чолгап алган дөнья. 2 класс.
9.05 Инглиз теле 1 нче уку елы.
9.55 Күп белүчеләр өчен күнегүләр.
10.40, 11.40 География. 6 класс.
11.10 Инглиз теле. 2 нче уку елы.
12.10 Нәфис фильм. «Монмартр түбәсе астында». 1 һәм 2 серияләр.
14.30 «Рамазан». Татар музыкасы фестивале.
17.00 РСФСР шәһәрләре телестудияләре.
17.25 Җиңүчеләр.
21.45 РСФСР Югары Советы сессиясендә.
23.15 Нәфис фильм. «Сай урын». 1 һәм 2 серияләр.

Чишмә авылында яшәүче кадерле әтиебез Хасибулла Җиһанша улы Гыйләҗевны 61 яшь тулу көне белән чын күңелдән кайнар котлыйбыз. Күп елларга ныклы сәламәтлек, җаннарына саулык-тынычлык, озын гомер, бәхет һәм тынычлык телибез.

БАЛАЛАРЫ, КИЛЕННӘРЕ, КИЯҮЛӘРЕ, ОНЫКЛАРЫ.

Суд залыннан

Сәүдә кагыйдәләрен бозган өчен

Күптән түгел «Спекуляция, законсыз сәүдә эшчәнлеге һәм сәүдәдән законсыз файдалану өчен җаваплылыкны көчәйтү» турындагы СССР Законы кабул ителүгә карамастан, районның кайбер сәүдә хезмәткәрләре сәүдә кагыйдәләрен бозуны дәвам итәләр, күбрәк шәхси интересларын гына кайгырталар. Шулай, Төрнәс авылындагы 12 нче «Промтоварлар» кибете мөдире булып эшләүче В.В. Сенькина сатып алучылардан дефицит товарларны яшереп кала. 1990 елның 5 декабре көнне сәгать 11дә тикшерү вакытында кибет складыннан гомуми бәясе 1927 сум 37 тиен тәшкил иткән 39 төрдәге товар табыла. Товарларның 1093 сумлыгын Сенькина үзе өчен, якыннары һәм танышлары өчен яшерә, ә калганлешен үзе әйткәнчә, ялгызы эшләгәнгә күрә сатуга чыгарып өлгермәгән була. Ир-атлар пальтосын бабасы өчен, балалар курткасын кызына, «Весна» магнитофонын үзенә, чәшке якалы хатын-кызлар пальтосы киленe—кибеттә җыештыручы Пискунова өчен калдырыла. Шулай ук үзенең дуслары, танышлары турында да кайгыртучанлык күрсәтә: аларга простыня, юрган тышлыклары, кыскасы, безнең вакытта дефицитка әйләнгән һәр әйберне саклап калырга тырышкан. Яшерелгән товарлар арасында одеколон, чит ил шампуне, бал кашыклары, рюмкалар һәм башкалар да урын алган иде. Булдыклы сатучы вак-төяк турында да онытмый. 1990 елның 31 октябрендә чыккан «Спекуляция, законсыз сәүдә эшчәнлеге һәм сәүдәдән законсыз файдалану өчен җаваплылыкны көчәйтү» турындагы СССР Законының 3 нче статьясы 1 нче бүлеге нигезендә Сенькина җинаять кылуда гаепләнде һәм аңа эш урыныннан 20 процент күләмендә хезмәт хакын хөкүмәт файдасына тапшырып, бер ел төзәтү эшләре билгеләп җәза бирелде. Җәзаның төре һәм күләме билгеләнгәндә халык суды тарафыннан хөкем ителүче Сенькинаның гаебен тануы, тәүбә кылуы, аңа язылган характеристика һәм беренче тапкыр хөкем ителүе игътибарга алынды.

Ә менә аның коллегасы Мәгъсүм Шәйхетдинович Вәлиев сатып алучылар исәбенә «акча ясарга» уйлаган, күрәсең. Ул «Төрнәс» совхозының беренче бригадасында «Ашамлыклар» кибетендә эшли.1990 елның 27 октябрендә килолы онны килограммы 28 тиенгә сата. Бәясе күрсәтелгән накладнойны алгач та, Вәлиев сатып алучыларга законсыз җыелган сумманы тулысынча түгел, бары тик яртысын гына кире кайтара. Һәм шулай итеп сатып алучыларны 28 сумга алдалый. Вәлиев әйтүенчә, ул бу акчаны транспорт һәм төяү-бушату эшендә тотылган чыгымнар өчен файдалана. Тик бу дөрескә туры килми, чөнки Вәлиевка бу төрдәге чыгымнарны тиешле бүлешмәләр буенча Мамык ХРТПсы түли.

РСФСР җинаятьләр кодексының 156 нче статьясы 1 нче бүлеге нигезендә Вәлиев җинаять кылуда гаепләнде һәм өч елга сәүдә системасында, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү, коммуналь хуҗалык предприятиеләрендә материаль-җаваплы урыннарда эшләү хокукыннан мәхрүм ителде.

Ф. ГАЛИМОВА,
халык судьясы.

Мөхәррир урынбасары **Р. Ә. АЙВАТУЛЛИН.**

Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы һәм КПССның район партия оешмасы.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны ФИДАНИЯ ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Асия МОРАТХАНОВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор— ЗӘЛФИЯ ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 32. Тираж 3.350.